

Мин Зәйнуллина Ленара Хәнәфи кызы.
Яңасала башлангыч мәктәбе укытучысы.

Безнең күрше авыл Яңасала зур авыл түгел. Шулай да Казан ханлыгы заманыннан бирле үк яшәп килгән бик борынгы авылларның берсе булганлыктан , җирендә - суында, тормыш – көнкүрешендә , риваятьләрендә халкыбыз тарихыннан хәтсез күп кадерле эзләр саклый алган. Ул эзләрдә халкыбызның асыл сыйфатлары чагыла. Авылның тарихы бай. Ул 1550 нче елларга барып тоташа.

Мин бу эшемдә сезне Янга – Сала җирлегендә яшәгән керәшен татарларының кием–салым һәм бизәнү әйберләре, бәйрәмнәре, йолалары , гореф – гадәтләре белән таныштырып үтәргә телим..

# Керәшен татарларының асыл мирасы

Хәтерләүдән курыкма син!
Үткәннәрне онытма син!
Бел син ерак әби – бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен,
Нинди уйлар, нинди моңнар
Безгә калдырып киткәнен.


Тирә-юньгә даның таралмаган,
Карталарда исемең юк синең.
Бар байлыгың урман тынлыгы да,
Бизәнгәнең энҗе чык синең.
Я ң а с а л а



Кем соң син?
Туган җир, авылың тарихын,
Нәселең агачы – шәҗәрәң,
Бабаңнар кемлеген белмәсәң,
Исемеңнең мәгънәсен төпченми,
Җисемеңнең асылына төшенми,
Хак биргән гомереңне үткәрсәң.



Татар керәшеннәренең
өй күренеше



Авылның тарихы бай.
Ул 1550 нче елларга барып тоташа.

# Кием - салым, бизәнү әйберләре





- Ак калпак, калпак — ак мамык җептән озын итеп бәйләнә

- Кашбау — очлы итеп тегелгән баш киеме.

Мәләнчек — тәңкәле һәм укалы һәртөрле баш киемнәре астына киеп калдырала торган чепчик формасындагы баш кияеме.






Чигәчә - чигә турысына тәңкәләр тезелгән баш кияеме.



Маңгай тәңкәсе





Ука чачак

Сүрәкә — мәләнчек һәм чигәчә өстеннән киелә торган баш киеме.



Сүрәкә канаты — сүрәкәнең арткы ягына беркетелеп, аркага төшеп тора, кулдан сугып эшләнгән яки ефәк материядән тегелгән була.



Башына *мәләнчек* өстеннән *чукол (баш яулыгы),* маңгай тәңкәсе һәм *чигәчә* бәйләгән. Тәңкәле күкрәк бизәгечләре кигән

Калфак өстеннән маңгаена ука-чачак бәйләгән кыз



# Яулык һәм бөркәнчекләр

**Түгәрәк җаулык — кара ефәк җеп белән чигелгән, кырыйла рына ука тотыл-ган, маңгай турысына тәңкәләр тезеп эшләнгән баш киеме.**









**Ак җаулык — олырак хатын-кызлар бәйли торган баш киеме.**

**Күшәгә — киндердән тегелгән бизәкле яулык.**

Дарай җаулык — өстән бөркәнә торган чәчәкле ефәк яулык





Тастар җаулык — яшь киленнәр бөркәнә торган яулык





Хатыннар яулыгы.

Күшәгә — киндердән тегелгән бизәкле яулык.



Хатынның башында: биек (квадрат формалы) мәләнчек калагы өстеннән сүрәкә бәйләнгән һәм хатыннар яулыгы уралган; сүрәкә астыннан маңгай читләренә төшеп торган чигәчәнең тәңкәле «канатлары» күренеп тора. Киң, дүрт рәт көмеш тәңкәләр тезеп эшләнгән муенса .

# Өс киемнәре һәм бизәнү әйберләре

Мыйтумар — өч-дүрт рәт тәңкә тезеп ясалган, бер иңбашыннан икенче як култык астына киелә торган укалы киң тасма, хәситә.



Сакал, изү, түшлек — тәңкәләр тезеп ясалган изү.







# Алҗапкыч



- Алмалы  алҗапкыч
- Чуптарлы алҗапкыч
- Чүпләмле алҗапкыч.









# Күлмәк



Калталы күлмәк — бала итәкле күлмәк.







Минчэт күлмәге —чиркәүдә никахлашканда киелә торган күлмәк.

# Ирләр киеме





**Өйдә тукылган алачадан тегелгән кайтарма якалы күлмәк**


**Ирләр күлмәкләре:**

Фабрика тукымасыннан тегелгән чигешле күлмәк






**Өйдә баскан ирләр эшләпәләре**



**Ирләр бүрекләре**

**Киез аяк киемнәре**








# Хатын - кыз аяк киемнәре

Киез итекләр














Җүкә аяк киемнәре (чабата-башмаклар)

# Йолалар





**Туй йолалары**

**Бала туу белән бәйле йолалар**

**Үлгән кешене күмү һәм искә алу йолалары**





# Нардуган

- Бабай булып җөрү
- Бабайчы багыты
- Нардуган такмагы
- Нардуган чабу
- Җөзек салу, балдак салу









# Май чабу

**Май арасы – май чабу көннәре**

**Май утырмасы – масленица  көннәрендә кызлар утырмасы**

**Май чабу - масленица  көннәрендә атларга утырып урам әйләнеп йөрү.**







**Атны җиксәң җик җакшысын,**
**Дугалардан бийек башлысын.**
**Җәрне сөйсән сөй җакшысын,**
**Ике күзе кара кашлысын  )**

# Бәрмәнчек


**Яз көне тал ботакларында бөреләр, йомшак йонлы тал "песиләре" барлыкка килгән, олы көн, ягъни пасхадан бер атна алдан үткәрелә торган бәйрәм.**








# Оло көн - Пасх



*«Хәлең ничек, керәшен кардәшем?»*

дигән очрашу кичәсе түгәрәк өстәл артында Яңасала мәдәни-ял үзәгендә шаулап-гөрләп үтте. Керәшен татарларының Пасха бәйрәме билгеләп үтелде. Китапхана мөдире Фәридә Борһанова бик матур итеп алып барды. Керәшен кардәшләребезне авыл җирлеге башлыгы Илфат Хаҗиахмәтов, ветераннар советы рәисе Оркыя Мөхәммәтҗанова кайнар котладылар. «Кәмеш чулпы» ветераннар ансамбленә кушылып әби-бабаларыбыз борынгы «Суда балык йөзәдер», «Бишмәтеңдә биш төймә»ләрне искә төшереп җырладылар. Өлкән ветеранныбыз мәдәният хезмәткәре Севия апа Газизова «Озата бармә» дигән моңлы җырны башкарды. Кәмеш чулпыларын чыңлатып мәдәни-ял үзәге мөдире Гөлназ Касыймова керәшен биюен биегәндә тамашачы тик кенә утыра алмады, бергә кушылып биеде. Әби-бабаларыбызга оныклары да үзләренең бик матур, шат җырларын бүләк иттеләр.

Китапханәче Фәридә авылдашыбыз, язучы Илгиз Кадыйровның «Яңасала», «Яшьлегем» дигән шигырьләрен укыды. Кичә чын мәгънәсендә бик матур, өешкан тәстә, җанлы үтте. Өстәл әзерләү өчен һәркем кулыннан килгән кадәр ярдәм итте.

Өлкәннәребез азга гына булса да дөнья мәшәкатьләреннән арынып, рәхәтләнеп күңел ачты.

***Фәридә БОРҺАНОВА,***
***«Бердәм Россия» сәяси партиясенең***
***Яңасала башлангыч оешмасы секретаре.***

**Хуҗабикәләр иртәнгә кадәр тәм-том өлгертә, әче һәм төчегә басылган камырлар-дан күмәч, крендель, пил-мән, шишәрә, тагын әлләниләр пешерә.**





**Пасха йомыркасы пешерү иң изге йолаларның берсе.**

# Оло көн - Пасха

- Төрле күңелле уеннар, күмәк күңел ачулар оештыралар .







- Пасха бер генә авылда да тагансыз узмый.











**Бу көнне өлкәннәрне мәдәният йортына чакырып кунак итәләр, керәшен җырлары, биюләре, йолалары күрсәтелә.**

# Җапрак бәйрәме

**Бу бәйрәм июнь аенының беренче атнасында үткәрелә, аны халыкта "җапырак бәйрәме" яки "кайын бәйрәме" дип тә йөртәләр, чөнки бу бәйрәм агачларның нәкъ яфрак ярган, матурланган чагына туры килә.**







# Питырау

Питырау бәйрәме июльнең 14-15 ләрендә үткәрелә.






Чушар күке күклидер,
Сука өстендә туктидыр,
Безнең уйын уйнислар
Питырау җиткис туктидыр

# Өмәләр






- Каз өмәсе
- Печән өсте
- Урак өсте
- Җеп эрләү

# "Гөргери кияүләре"

спектакленнән күренешләр













# "Көмеш чулпы"

**ветераннар ансамбле**











# Яңасала үзешчәннәре – район сәхнәсендә







